ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.11.2016 Казан ш. № 7-15/т

Татарстан Республикасы “Бөгелмә муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә “Бөгелмә АТП” җаваплыгы чикләнгән җәмгыять тарафыннан гомуми файдаланудагы шәһәр яны автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны билгеләү турында

“Россия Федерациясендә автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты белән пассажирлар һәм багажны даими алып баруларны оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү” турындагы 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ санлы, “Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы” 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ санлы Россия Федерациясе законнарына, “Бәяләрне (тарифлар) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында” 1995 елның 7 мартындагы 239 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына нигезләнеп, “Росия Федерациясендә автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр пассажир транспорты белән пассажирлар һәм багажны даими алып баруларны оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү” Федераль законын тормышка ашыру” турындагы 2015 елның 26 декабрендәге 107-ЗРТ санлы Татарстаны Республикасы законы белән, 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы “Бөгелмә муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә “Бөгелмә АТП” җаваплыгы чикләнгән җәмгыять тарафыннан гомуми файдаланудагы шәһәр яны автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж алып

баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифларны әлеге карарның кушымтасы нигезендә билгеләргә.

2. Түбәндәге карар рәсми рәвештә басылып чыккач 10 көннән соң гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча дәүләт комитетының
03.11.2016 № 7-15/т
карарына кушымта

Татарстан Республикасы “Бөгелмә муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә
“Бөгелмә АТП” җаваплыгы чикләнгән җәмгыять тарафыннан
гомуми файдаланудагы шәһәр яны автомобиль транспортында
пассажирлар һәм багаж алып баруга максималь дәрәҗәдә чик тарифлар

| № п/п | Хезмәт күрсәтү төре | Үлчәү берәмлеге | Тариф (НДСтан тыш) |
|---|---|---|---|
| 1 | Пассажирларны автобуста алып бару | сум/пасс./км | 2,00 |
| 2 | Автобуста бер урынлы багаж алып бару | сум./км | 0,30 |

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештыру һәм җайга салу бүлеге